СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30.12.2019 г.Зеленодольск № 471

Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге субсидияләр һәм (яки) башка бюджетара трансфертлар, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләре турында

Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге субсидияләр һәм (яки) башка бюджетара трансфертлар, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләре турында «Зеленодольск муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе О.П. Дёгтева мәгълүматын тыңлап һәм фикер алышканнан соң, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142 статьясы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар итте:**

1. Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге субсидияләр һәм (яки) башка бюджетара трансфертлар, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган, республика конкурсында җиңүчеләр дип танылган, шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән авыл җирлекләренә һәм шәһәр җирлекләренә грантлар бирү өчен, финанс белән тәэмин итү чыганагы-

Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнеше булган башка бюджетара трансфертлар Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән авыл җирлекләре һәм шәһәр җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен 2 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге субсидияләр һәм (яки) башка бюджетара трансфертлар, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру өлешендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне башкарганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең чыгым йөкләмәләренә башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен 3 нче кушымта нигезендә расларга,

4. Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге субсидияләр һәм (яки) башка бюджетара трансфертлар, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен матди бүләкләүгә бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләре 4 нче кушымта нигезендә расларга.

5. Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге субсидияләр һәм (яки) башка бюджетара трансфертлар, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны үткәрүгә территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләрен башкару өлешендә бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләре 5 нче кушымта нигезендә расларга,

6. Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге субсидияләр һәм (яки) башка бюджетара трансфертлар, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында җиңүчеләр һәм призерлар дип табылган тиешле җирлекләр территориясендә теркәлгән территориаль иҗтимагый үзидарәләргә грантлар бирүгә бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен 6 нчы кушымта нигезендә расларга,

7. Әлеге карарның нигезләмәләре, 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына бюджетлардан башлап, бюджетларны төзегәндә, раслаганда һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

8. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы урынбасары** **Э.Р. Кадникова**

Зеленодольск шәһәре Советының
2019 елның 30 декабрендәге 471
номерлы карарына 1 нче кушымта

. Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге субсидияләр һәм (яки) башка бюджетара трансфертлар, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләре

1. Әлеге кагыйдәләр Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге субсидияләр һәм (яки) башка бюджетара трансфертлар, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар (алга таба – башка бюджетара трансфертлар, җирлек) максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итүне стимуллаштыру максатларында җирлекләр бюджетларына бирелә.

3. Башка бюджетара трансфертлар җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар исәбеннән җирлекләр бюджетларына бирелә.

4. Башка бюджетара трансфертлар тиешле финанс елына һәм план чорына Зеленодольск муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында каралган максатларга билгеләнгән тәртиптә бирелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

5. Җирлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары булып түбәндәгеләр тора:

а) җирлектә (җирлек составына керә торган торак пунктта) гражданнарга үзара салым кертү турында җирле референдумда (гражданнар җыенында) карар кабул итү;

б) җирлектә (җирлек составына керә торган торак пунктта) гражданнарның үзара салымын кертү турындагы карарда гражданнарның үзара салым акчаларын тотуның конкрет юнәлешләре булу;

в) башка бюджетара трансфертлар һәм гаризаларга кушып бирелә торган документларны җирлекләрнең Башкарма комитетлары тарафыннан үз вакытында тапшыру;

г) җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясында каралган җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар бирүнең төп шартларын үтәү.

6. Җирлекләрнең Башкарма комитетлары агымдагы финанс елның I кварталы тәмамланганнан соң 10 календарь көн эчендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына түбәндәге документларны тапшыралар:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 декабрендәге 909 номерлы карары белән расланган Гражданнарга үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 1 нче кушымтасы нигезендә башка бюджетара трансфертлар бирүгә гариза бирү;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча закон нигезендә агымдагы финанс елына кадәрге елларда кабул ителгән карарларның күчермәләре;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 декабрендәге 909 номерлы карары белән расланган гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 нче кушымтасы нигезендә хисап чорында Татарстан Республикасы бюджетының үтәлеше турында хисаплардан өземтәләр.

7. Җирлек өчен башка бюджетара трансфертлар күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$MT = 4 \times (CC - Ccf),$$

биредә:

MT - җирлеккә башка бюджетара трансферт күләме, сум;

CC - җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән гражданнар үзара салымын гамәлгә кертү турындагы карар нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җирлек бюджетына кергән гражданнар акчасының гомуми күләме, сум;

Ccf - башка бюджетара трансфертлар бирү максатларында элек исәпкә алынган, җирле референдумда (гражданнар җыенында) гражданнарның үзара салымын гамәлгә кертү турындагы кабул ителгән карар нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен җирлек бюджетына кергән гражданнарның үзара салым акчасының күләме, сум.

8. Җирлекләр бюджетлары арасында башка бюджетара трансфертларны бүлү Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль хокукый акты белән раслана.

9. Җирлекнең Башкарма комитеты Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән срокларда һәм форма буенча башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап тапшыра.

10. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык җирлекнең Башкарма комитетына йөкләнә.

11. Башка бюджетара трансфертлар җирлек бюджетларына җирлекнең башкарма комитеты тарафыннан тәкъдим ителә торган гариза нигезендә җирле бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең территориаль органнары счетларына күчерелә.

12. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары бозылган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясенең бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә Зеленодольск муниципаль районы бюджеты кеременә күчерелергә тиеш.

13. Башка бюджетара трансфертларны бирү елыннан соң киләсе елның 1 гыйнварына файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларның калганы, Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

14. Башка бюджетара трансфертлар максатчан характерда була һәм, әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш, башка максатларда файдаланыла алмый.

15. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдалануны тикшереп торуны, законнар нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты һәм муниципаль финанс контроле органнары гамәлгә ашыра.

Зеленодольск муниципаль район
Советының 2019 елның 30 декабрендәге
471 номерлы карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган, республика конкурсында җиңүчеләр дип танылган, шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән авыл җирлекләренә һәм шәһәр җирлекләренә грантлар бирү өчен, финанс белән тәэмин итү чыганагы-Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнеше булган башка бюджетара трансфертлар, Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән авыл җирлекләре һәм шәһәр җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләре

1. Әлеге кагыйдәләр Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган, республика конкурсында җиңүчеләр дип танылган, шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән авыл җирлекләренә һәм шәһәр җирлекләренә грантлар бирү өчен, финанс белән тәэмин итү чыганагы-Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнеше булган башка бюджетара трансфертлар, Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән авыл җирлекләре һәм шәһәр җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар (алга таба – башка бюджетара трансфертлар, җирлекләр) максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселогы нигезендә төзелгән авыл җирлекләренә һәм шәһәр җирлекләренә грантлар бирүгә республика конкурсында җиңүчеләр дип танылган җирлекләр бюджетларына бирелә:

халыкның тормыш сыйфатын күтәрү буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлеген стимуллаштыру;

җирлекләрнең социаль әһәмиятле проблемаларын хәл итү;

җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен өстәмә ресурсларны җәлеп итү механизмнарын камилләштерү.

3. Башка бюджетара трансфертлар җирлекләр бюджетларына - грант алучыларга Татарстан Республикасы бюджетыннан җирлекләрнең тормыш-көнкүрешен тәэмин итү объектларының матди-техник базасын ныгытуга, җирлекләрнең социаль инфраструктура объектларын һәм тышкы төзекләндерүгә, җирлекләрнең социаль әһәмиятле башка мәсьәләләрен хәл итүгә бирелә торган башка бюджетара трансфертлар исәбеннән бирелә.

4. Башка бюджетара трансфертлар тиешле финанс елына һәм план чорына Зеленодольск муниципаль районы бюджетында каралган бюджет

ассигнованиеләре һәм әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында каралган максатларга билгеләнгән тәртиптә бирелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

5. Җирлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү шарты булып тора:

җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясында каралган җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар бирүнең төп шартларын үтәү.

6. Грант алучыларга түләнгән грантлар саны башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткече булып тора.

7. Грантлар күләме Татарстан Республикасы норматив хокукый акты белән билгеләнә.

8. Җирлекләр бюджетлары арасында башка бюджетара трансфертларны бүлү Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль хокукый акты белән раслана.

9. Җирлекнең башкарма комитеты Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы һәм Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты арасында төзелгән килешүдә каралган вакыт эчендә һәм форма буенча башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап тапшыра.

10. Тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына йөкләнә.

11. Башка бюджетара трансфертлар җирлекләр бюджетларына федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең җирле бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен җирлек Башкарма комитеты тарафыннан бирелә торган гариза нигезендә ачык территориаль органнары счетларына күчерелә.

12. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә Зеленодольск муниципаль районы бюджеты кеременә күчерелергә тиеш.

13. Башка бюджетара трансфертларны бирү елыннан соң киләсе елның 1 гыйнварына файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларның калганы, Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемендә кире кайтарылырга тиеш.

14. Башка бюджетара трансфертлар максатчан характерга ия һәм, әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш, башка максатларда кулланыла алмый.

15. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдалануны тикшереп торуны, законнар нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты һәм муниципаль финанс контроле органнары гамәлгә ашыра.

Зеленодольск муниципаль район
Советының 2019 елның 30 декабрендәге
471 номерлы карарына 3 нче кушымта

Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге субсидияләр һәм (яки) башка бюджетара трансфертлар, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру өлешендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне башкарганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең чыгым йөкләмәләренә башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләре

1. Әлеге кагыйдәләр Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге субсидияләр һәм (яки) башка бюджетара трансфертлар, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру өлешендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне башкарганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең чыгым йөкләмәләренә башка бюджетара трансфертлар бирүнең(алга таба – башка бюджетара трансфертлар, җирлек) максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру өлешендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен гамәлгә ашыру максатларында җирлекләр бюджетларына бирелә.

3. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру өлешендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен гамәлгә ашыруга Зеленодольск муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субсидияләр һәм (яисә) башка бюджетара трансфертлар исәбеннән җирлекләр бюджетларына бирелә.

4. Башка бюджетара трансфертлар тиешле финанс елына һәм план чорына Зеленодольск муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында каралган

максатларга билгеләнгән тәртиптә бирелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

5. Җирлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү шарты булып тора:

җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясында каралган җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар бирүнең төп шартларын үтәү.

6. Җирлекләр бюджетлары арасында башка бюджетара трансфертларны бүлү Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль хокукый акты белән раслана.

7. Җирлек Башкарма комитеты Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына субсидияләр һәм (яки) башка бюджетара трансфертлар биргән тиешле министрлык һәм Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты арасында килешүдә каралган срокта һәм форма буенча башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап тапшыра.

8. Тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитетына йөкләнә .

9. Башка бюджетара трансфертлар җирлекләр бюджетларына федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең җирле бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен җирлек Башкарма комитеты тарафыннан бирелә торган гариза нигезендә ачык территориаль органнары счетларына күчерелә.

10. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә Зеленодольск муниципаль районы бюджеты кеременә күчерелергә тиеш.

11. Башка бюджетара трансфертларны бирү елыннан соң киләсе елның 1 гыйнварына файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларның калганы, Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемнә кире кайтарылырга тиеш.

12. Башка бюджетара трансфертлар максатчан характерга ия һәм, әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш, башка максатларда кулланыла алмый.

13. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдалануны тикшереп торуны, законнар нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты һәм муниципаль финанс контроле органнары гамәлгә ашыра.

Зеленодольск муниципаль район
Советының 2019 елның 30 декабрендәге
471 номерлы карарына 4 нче кушымта

Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге субсидияләр һәм (яки) башка бюджетара трансфертлар, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен матди бүләкләүгә бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләре

1. Әлеге кагыйдәләр Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге субсидияләр һәм (яки) башка бюджетара трансфертлар, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен матди бүләкләүгә бюджетара трансфертлар бирү (алга таба – башка бюджетара трансфертлар, җирлек) максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы бюджетыннан җирлекләрнең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен матди бүләкләүгә бәйле максатларга бирелә торган субсидияләр һәм (яисә) башка бюджетара трансфертлар исәбеннән бирелә.

3. Башка бюджетара трансфертлар тиешле финанс елына һәм план чорына Зеленодольск муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында каралган максатларга билгеләнгән тәртиптә бирелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә җирлекләр бюджетларына бирелә.

4. Җирлекләр бюджетлары арасында башка бюджетара трансфертларны бүлү Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль хокукый акты белән раслана.

5. Башка бюджетара трансфертлар бирү шарты булып түбәндәгеләр тора:

а) асылда эш белән тәэмин ителгән штат берәмлекләре;

б) җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясында каралган җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар бирүнең төп шартларын үтәү.

6. Җирлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар җирле бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең территориаль органнары счетларына күчерелә.

7. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемено күчерелергә тиеш.

8. Башка бюджетара трансфертларны бирү елыннан соң киләсе елның 1 гыйнварына файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларның калганы, Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

9. Башка бюджетара трансфертлар максатчан характерга ия һәм, әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш, башка максатларда кулланыла алмый.

10. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдалануны тикшереп торуны, законнар нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты һәм муниципаль финанс контроле органнары гамәлгә ашыра.

Зеленодольск муниципаль район
Советының 2019 елның 30 декабрендәге
471 номерлы карарына 5 нче кушымта

Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге субсидияләр һәм (яки) башка бюджетара трансфертлар, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны үткәрүгә территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләрен башкару өлешендә бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләре

1. Әлеге кагыйдәләр Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге субсидияләр һәм (яисә) башка бюджетара трансфертлар, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны үткәрүгә территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләрен башкару өлешендә бюджетара трансфертлар бирү (алга таба – башка бюджетара трансфертлар, җирлек) максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели

2. Тиешле җирлекләр территориясендә теркәлгән территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру максатларында җирлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирелә.

3. «2014 - 2024 елларга Татарстан Республикасын икътисадый үстерү һәм аның инновацион икътисады» дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә, «2014 - 2024 елларга Татарстан Республикасын икътисадый үстерү һәм аның инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 октябрендәге 823 номерлы карары белән расланган башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараны уздыру өчен чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә бирелә торган башка бюджетара трансфертлар исәбеннән җирлекләр бюджетларына бирелә,

4. Башка бюджетара трансфертлар тиешле финанс елына һәм план чорына Зеленодольск муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында каралган

максатларга билгеләнгән тәртиптә бирелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

5. Башка бюджетара трансфертлар биру өчен җирлекләрне сайлап алу критерияләре булып түбәндәгеләр тора:

җирлек территориясендә теркәлгән территориаль иҗтимагый үзидарәләр (алга таба – ТИҮ) булуы;

территориаль иҗтимагый үзидарәләрдә (ТИҮдә) берләшкән халык саны, шәһәр җирлекләре өчен - кимендә 80 кеше, авыл җирлекләре өчен - 2 000 кешедән ким түгел.

6. Җирлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар биру шартлары булып түбәндәгеләр тора:

а) җитәкчеләренә компенсация түләү гамәлгә ашырыла торган ТИҮ исемлеген раслау турында җирлек башкарма комитеты күрсәтмәсенең булуы.;

б) җирлекнең билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән муниципаль хокукый актының булуы, ТИҮ җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру буенча чыгым йөкләмәләрен билгели;

в) җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясында каралган җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар бирүнең төп шартларын үтәү.

7. ТҖҮ җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыруга ярдәм күрсәтелә торган башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткече булып тора. Нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешүне бәяләү Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан җирлек башкарма комитеты тарафыннан тапшырылган хисапларга үткәрелгән анализ нигезендә тормышка ашырыла.

8. Башка бюджетара трансфертлар алу өчен җирлекләрнең башкарма комитетлары Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына түбәндәгеләрне тапшыралар:

башка бюджетара трансфертлар бирүгә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча гариза;

ТИҮ оештыру документлары күчермәләре;

ТИҮ җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өчен финанс ихтыяҗын исәпләү һәм нигезләү.

Документлар җирлек тарафыннан кәгазь һәм электрон формада тапшырыла.

9. Җирлек бюджетына башка бюджетара трансфертлар күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$P = (N_1 \times R_1) \times 15 + (N_2 \times R_2) \times 15,$$

биредә:

P-җирлекнең ТИҮ җитәкчеләренә компенсация түләүләрен тормышка ашыру өчен финанс ихтыяҗы, сум;

$N_1$-юридик затлар булган ТИҮләр саны, берәмлек;

$N_2$-юридик затлар булмаган ТИҮләр саны, берәмлек;

$R_1$-территориаль иҗтимагый җирле үзидарә җитәкчесенә шәһәр (авыл) җирлеге өчен 13 020,0 сум күләмендә компенсация түләү күләме;

$R_2$-территориаль иҗтимагый җирле үзидарә җитәкчесенә шәһәр (авыл) җирлеге өчен 10 000 сум күләмендә компенсация түләү күләме.

10. Җирлекләр бюджетлары арасында башка бюджетара трансфертларны бүлү Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль хокукый акты белән раслана.

11. Җирлекнең башкарма комитеты Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы һәм Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты арасында төзелгән килешүдә каралган вакыт эчендә һәм форма буенча башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап тапшыра.

12. Тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитетына йөкләнә.

13. Башка бюджетара трансфертлар җирлекләр бюджетларына федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль органнары счетларына җирлек башкарма комитеты тарафыннан бирелә торган заявка нигезендә җирле бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган счетларына күчерелә.

14. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә Зеленодольск муниципаль районы бюджеты кеременә күчерелергә тиеш.

15. Башка бюджетара трансфертларны бирү елыннан соң киләсе елның 1 гыйнварына файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларның калганы, Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш.

16. Башка бюджетара трансфертлар максатчан характерга ия һәм, әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш, башка максатларда кулланыла алмый.

17. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдалануны тикшереп торуны, законнар нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты һәм муниципаль финанс контроле органнары гамәлгә ашыра.

Зеленодольск муниципаль район
Советының 2019 елның 30 декабрендәге
471 номерлы карарына 6 нчы кушымта

Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге субсидияләр һәм (яки) башка бюджетара трансфертлар, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында җиңүчеләр һәм призерлар дип табылган тиешле җирлекләр территориясендә теркәлгән территориаль иҗтимагый үзидарәләргә грантлар бирүгә бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләре

1. Әлеге кагыйдәләр Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге субсидияләр һәм (яки) башка бюджетара трансфертлар, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында җиңүчеләр һәм призерлар дип табылган тиешле җирлекләр территориясендә теркәлгән территориаль иҗтимагый үзидарәләргә грантлар бирүгә башка бюджетара трансфертлар бирүнең (алга таба – башка бюджетара трансфертлар, җирлек) максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасында территориаль иҗтимагый үзидарәләрне үстерү һәм гражданнарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җәлеп итү максатларында җирлекләр бюджетларына бирелә.

3. Башка бюджетара трансфертлар «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе»республика конкурсы җиңүчеләре һәм призерлары дип танылган территориаль иҗтимагый үзидарәләргә грантлар бирү өчен Зеленодольск муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган башка бюджетара трансфертлар исәбеннән җирлекләр бюджетларына бирелә.

4. Башка бюджетара трансфертлар тиешле финанс елына һәм план чорына Зеленодольск муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында каралган максатларга билгеләнгән тәртиптә бирелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

5. Җирлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү шарты булып түбәндәгеләр тора:

а)җирлек территориясендә теркәлгән «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында

җиңүчеләргә һәм призерларга билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән муниципаль хокукый актның булуы.

б) җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясында каралган җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар бирүнең төп шартларын үтәү.

6. Республика конкурсында җиңүчеләргә һәм призерларга түләнгән грантлар саны башка бюджетара трансфертлардан нәтиҗәле файдалану күрсәткече булып тора

7. Грантлар күләме Татарстан Республикасы норматив хокукый акты белән билгеләнә.

8. Җирлекләр бюджетлары арасында башка бюджетара трансфертларны бүлү Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль хокукый акты белән раслана.

9. Җирлекнең Башкарма комитеты Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы һәм Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты арасында төзелгән килешүдә каралган вакыт эчендә һәм форма буенча башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап тапшыра.

10. Тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына йөкләнә.

11. Башка бюджетара трансфертлар җирлекләр бюджетларына федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль органнары счетларына җирлек башкарма комитеты тарафыннан бирелә торган гариза нигезендә җирле бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган счетларына күчерелә.

12. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә Зеленодольск муниципаль районы бюджеты кеременә күчерелергә тиеш.

13. Башка бюджетара трансфертларны бирү елыннан соң киләсе елның 1 гыйнварына файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларның калганы, Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемена кире кайтарылырга тиеш.

14. Башка бюджетара трансфертлар максатчан характерга ия һәм, әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш, башка максатларда кулланыла алмый.

15. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдалануны тикшереп торуны, законнар нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты һәм муниципаль финанс контроле органнары гамәлгә ашыра.